**20-30 нчы елларда зурлар өчен татар теле дәреслекләре**

1921 елда татар теле рус теле белән бер дәрәҗәдәге дәүләт теле итеп игълан ителгәннән соң [2: 4], рус телле балаларны гына түгел, зурларны да татар теленә өйрәтү ихтыяҗы барлыкка килә. Башлангыч яки урта мәктәпләр өчен чыгарылган дәреслекләр дә беренче елларда бу максатка хезмәт итә. 20-30 нчы елларда руслар өчен татар теле дәреслекләренең зур күпчелеге күренекле галим, педагог һәм методист, татар телен ана теле һәм икенче тел буларак укыту, телләрне чагыштырып өйрәнү өлкәләренә гаять зур өлеш керткән Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиев тарафыннан төзелә. Ул үзе генә яки Р.Газиз, Х.Бәдигый һәм З.Бәдигуллиннар белән берлектә башлангыч һәм урта мәктәп укучылары, шулай ук зурлар өчен татар теленнән күп санлы дәреслекләр әзерләп чыгара.

1925 елда М.Х.Корбангалиев һәм Р.С.Газизов тарафыннан "Русларга татар теле өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек” төзеп бастырыла, 1928 елда аның икенче басмасы дөнья күрә. Дәреслекнең максаты итеп татар булмаган һәм үз телләрендә яхшы укый-яза белгән зурларны татар теленә өйрәтү куела. Ул чорда төп методлар итеп саналган табигый (натураль) һәм тәрҗемәле-грамматика методларына кыскача күзәтү ясалганнан соң, зурларны бу дәреслек белән укытканда, әлеге ике методны берләштереп куллану кирәклеге ассызыклана. Авторлар фикеренчә, абстракт төшенчәләрне абстракт мисаллар белән аңлатуга караганда, әлеге сүзне укучының туган теленә тәрҗемә итү һәм ике телдәге грамматик формаларын чагыштыру күбрәк нәтиҗә бирә [2: II-III]. Шулай итеп, зурларны укытканда, телнең аерым сүзләрен үзләштерүләренә караганда, тел әйләнмәләре һәм сөйләм формаларына игътибар итүнең мөһимлеге ассызыклана. Моннан чыгып, дәреслекнең беренче тугыз дәресе җанлы сөйләшү алып бару өчен билгеләнә, ягъни баштагы дәресләр-

дә үк уку һәм язуга өйрәтү максат итеп куелмый. Бу эш укучыларны татар сүзләрен (сүзләрдәге авазлар кушылмасын) дөрес әйтергә күнектерү һәм татар сөйләмендәге авазларны дөрес тотып алуларына ирешү максатына хезмәт итә. Дәреслекнең “Сүз башы”нда әйтелгәнчә, шуннан соң укучылар татар хәрефләрен җиңел үзләштерәләр, укытучыга, хәреф өйрәткәндә, күп көч куярга туры килми. Сөйләшү дәресләре шул рәвешчә бөтен курс дәвамында үткәрелергә тиеш була, шулай итеп, өйрәтүнең мондый системасында вакытка зур экономия ясала [3: III].

Дәреслекнең төзелү системасы түбәндәгечә.

Беренче дәрестә татарча һәм русча иң кирәкле әйберләрнең исемнәре бирелгән. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| *бу – это* | *такта – доска* |
| *кем – кто* | *дәфтәр – тетрадь* |
| *нәрсә – что* | *бур – мел* |
| *китап – книга* | *букча – сумка* һ.б. |

Соңга таба, шул ук сүзләрдән чыгып, татарча сораулар һәм аларга җаваплар китерелә:

*Бу нәрсә? – Бу – китап. Бу – карандаш. Бу – такта* һ.б.

Икенче дәрестә, беренче дәрестә бирелгән сүзләрдән чыгып, кайда дигән сорауга җавап булган җөмләләр язылган:

*Китап кайда? – Китап букчада. Бур тактада. Дәфтәр букчада* [3: 7].

Моннан соңгы 7 дәрестә (7-13 б.) кеше әгъзаларының исемнәре белән таныштыруга юнәлтелгән төрле исемнәр бирелгән. Шушы исемнәрдән чыгып, сораулар һәм аларга җаваплар язылган. Укучыларның сөйләм телләрен үстерү максатыннан чыгып, сорауларга җаваплар бирү һәм язылып бетмәгән җөмләләрне тәмамлау кебек күнегүләр тәкъдим ителә, ә дәрес азагында, кагыйдә рәвешендә, бөтен

дәрестәге материалга нәтиҗә чыгарыла һәм әлеге нәтиҗәләр рус телендә биреләләр. Барлык кагыйдә-аңлатмалар да рус грамматикасы белән чагыштыру нигезендә төзелгән.

Алдагы 17 дәрес “Уку-язуга өйрәтү дәресләре” (13-39 б.) дип атала, алфавитны үтү һәм татар теленең төп грамматик формалары белән танышу максатын күздә тота. Һәр дәрес башында укучылар өчен таныш булмаган сүзләрнең тәрҗемәләре биреп барыла, дәрес ахырында рус телендә нәтиҗәләр тәкъдим ителә. Татар телендәге килеш кушымчаларын һәм фигыльнең өч заман формасын үтеп бетергәч исә, 12 нче дәрестән башлап, әзер кагыйдәләр бирелми, ә авторларның “Опыт краткой практической грамматики татарского языка” китабындагы параграфларга мөрәҗәгать итәргә кушыла.

III бүлектә (39-50 б.) йорт кирәк-яракларына багышланган, ә IV бүлектә (51-117 б.) ел фасыллары белән бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы турында һәм Татарстан сәнәгатенең кайбер тармаклары хакында текстлар (авторлар аларны мәкалә дип атый – З.К.) бирелгән.

Аерым дәресләрдә яңа сүзләрнең тәрҗемә итеп бирелүеннән тыш, дәреслек ахырында алфавит нигезендә төзелгән 18 битлек сүзлек тә урын алган.

Үткәннәрне кабатлау һәм яхшырак истә калдыру максатыннан чыгып, төрле эчтәлекле күнегүләр дә урнаштырылган: татар хәрефләре белән сүзләрне уку һәм язу, аерым сүзләрдән җөмләләр төзү, текстларны тәрҗемә итү һәм үз исемеңнән сөйләргә яки язарга өйрәнү һ.б. Телдән һәм язма биремнәр арасында затны үзгәртеп сөйләргә яки язарга кушылган бирем өстенлек ала.

Дәреслекне төзегәндә, оста методист һәм педагог буларак, М.Х.Корбангалиевның әле укучыларның телне белмәвен һәм алар читенсенә торган барлык якларны да искә алып эш иткәнлеге күренә. “Чит тел”не өйрәтә башлаганда, әле башта ук укырга һәм язарга

өйрәтергә, яки алфавит белән таныштырырга керешелми, бәлки элек теге яки бу сүзләрне әйтә белергә, авазларның татарча дәрес әйтелешенә ирешүгә игътибар ителә. Шуннан соң гына алфавит белән таныштыру, гомумән, укырга-язарга өйрәтүгә урын бирелгән, шуның белән бергә, сөйләм телен үстерү һәм грамматика буенча белем бирү бергә бәйләнеп алып барылырга тиешлек күздә тотылган һәм дәреслек тә шуңа яраклаштырып төзелгән [1: 104-105].

М.Корбангалиев техникум, рабфак, вуз һәм втузлар өчен 1934 елда “Татарлардан башкалар өчен татар теле дәреслеге”н төзеп бастыра. Бу дәреслектә морфология һәм синтаксис буенча тулы мәгълүмат бирелә һәм татар әдәбиятыннан да үрнәкләр китерелә. Грамматиканың бүлекләре аерым-аерым бирелгән булса да, материалның һәм күнегүләрнең урыны һәм эчтәлегенә караганда, уку, язу, сөйләм телен үстерү һәм грамматика буенча белем бирүнең бергә бәйләнеп барырга тиешлеге, шулай ук дөрес әйтелешкә дә һәрвакыт игътибар бирү кирәклеге аңлашыла.

Татар теленең күп кенә грамматик формалары, бигрәк тә морфология бүлеге, рус теле белән чагыштырылып бирелә, ягъни М.Корбангалиев, мәктәпләрдәге кебек үк, урта һөнәри һәм югары уку йортларында да рус теле белән татар телен чагыштырма рәвештә өйрәнүне алга куя. Морфологияне өйрәтүгә багышланган бүлек (6-121 б.) синтаксис өлешенә (122-151 б.) карaганда күпкә зуррак, аның беренче битләрендә (6-8 б.) шулай ук татар алфавиты, татар теленең авазларын төркемләү, сузык һәм тартык авазларның калын яки нечкә әйтелешенә багышланган, ягъни фонетикага караган материал да урын алган.

Дәреслекнең төзелешеннән күренгәнчә, иң элек татарча текст яки “Сөйләшү” дигән исем белән диалог бирелә, аннан соң рус телендә грамматик нәтиҗәләр чыгарыла, иң соңыннан, үтелгән материалны хәтердә калдыру максаты белән, төрле характердагы күнегүләр урын ала, аларның эчтәлеге сөйләм телен үстерү, язуга өйрәтү һәм грамматик

күзәтүләр ясауга юнәлдерелгән. Аерым алганда, рус теленнән татарчага яки киресенчә тәрҗемә итү, төрле фигыль формалары ясау яки төрләндерү, төшереп калдырылган сүзләрне куеп язу кебек эш төрләренә зур урын бирелгән, шулай ук сөйләшү өчен яки сүз төркемнәренең төрләнеше буенча таблицалар һәм схемалар да китерелгән. Тагын шунысы игътибарны җәлеп итә: текстларның бер өлеше көндәлек тормышның гадәти күренешләренә багышланган булса, яңа идеология һәм сәясәткә бәйлеләре күбрәк урынны алып тора. Әдәби материаллар да Ленин һәм Сталинга багышланган текстлар белән башланып китә, шуннан соң гына татар әдипләре хакында кыскача мәгълүмат бирелеп, әсәрләреннән өзекләр китерелә.

Йомгак ясап әйткәндә, 20-30 нчы еллардагы дәреслекләр комплекслылык системасына, табигый һәм тәрҗемәле-грамматика методларына нигезләнеп төзелә. Күпчелек дәреслекләрнең “Сүз башы”нда татар телен укыту буенча җентекле методик күрсәтмәләр бирелә, укыту программалары исә сан ягыннан күп булмый. 20 нче елларда башлангыч сыйныфлар яки урта мәктәп балалары өчен чыгарылган татар теле дәреслекләре югары уку йортларында һәм зурлар курсларында укыту өчен дә кулланыла, 30 нчы елларда исә дәреслекләр укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм эзлекле рәвештә бастырыла башлый, ләкин аларга үз чоры идеяләре белән сугарылган булу, марксистик теорияне, хезмәт процессларын нигез итеп алу хас.

Әдәбият

1. Вәлеева Ф.С. Халкына багышланган гомер: Мөхетдин Корбангалиевнең татар телен укыту буенча методик системасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 143 б.

2. Кириллова З.Н. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20-30 нчы еллар). – Казан: Мастер Лайн, 2000. – 208 б.

3. Корбангалиев М., Газизов Р. Русларга татар теле өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек. 1 нче кисәк. – Казан: Татар. матб.- нәшр. комб.,

1925. – 135 б.